Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Камыш авылы Волейбол урамы гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

19 октябрь, 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Камыш авылы Волейбол урамы гражданнарының 2024 елның 19 октябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 19 (унтугыз).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 14 (ундүрт).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 14 (ундүрт).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Богородский авыл җирлеге Камыш авылы Волейбол урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә (Волейбол ур.) гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Богородский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Д.Ю. Булыгин